ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 г. Казань № 766-162/кс-2023

Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама җылылык-электр үзәге (ПТК-1) «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте филиалы өчен 2024-2028 елларга эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 №60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

әлеге карарның 1-2 нче кушымталарына ярашлы рәвештә, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама җылылык-электр үзәге (ПТК-1) «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте филиалы (алга таба – «ТГК-16» АҖ) өчен эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар;

салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ өчен эчә торган суга, техник суга һәм су агызуга 2024-2028 елларга, әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын.

2. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 766-162/кс-2023
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ өчен
2024 елга эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Чор | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|---|
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алынмыйча күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 37,26 | 6,31 | 17,37 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 48,28 | 6,31 | 18,19 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 766-162/кс-2023
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ өчен эчә торган суга, техник суга һәм су агызуга 2025-2028 елларга* календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Чор | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|---|
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алынмыйча күрсәтелгән) | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 45,22 | 6,31 | 18,19 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 45,22 | 7,71 | 18,71 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 45,22 | 7,29 | 18,71 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 47,47 | 7,29 | 19,72 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 47,47 | 7,29 | 19,72 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 47,56 | 7,86 | 20,31 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 47,56 | 7,86 | 20,31 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 49,95 | 7,89 | 21,40 |

<*> 2025-2028 елларга эчәргә яраклы суга, техник суга һәм су агызуга тарифларга ел саен төзәтмәләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә уздырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 766-162/кс-2023
карарына 3 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ТГК-16» АҖ өчен
эчә торган суга, техник суга һәм су агызуга тарифларны 2024-2028 елларга
озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе*** | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы*** |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2024 | 939,38 | - | - | 2,27 | - |
| | | 2025 | - | 1 | - | 2,27 | - |
| | | 2026 | - | 1 | - | 2,27 | - |
| | | 2027 | - | 1 | - | 2,27 | - |
| | | 2028 | - | 1 | - | 2,27 | - |
| 1.2 | Техник су | 2024 | 20 348,94 | - | - | 2,51 | - |
| | | 2025 | - | 1 | - | 2,51 | - |
| | | 2026 | - | 1 | - | 2,51 | - |
| | | 2027 | - | 1 | - | 2,51 | - |

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе*** | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы*** |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2028 | - | 1 | - | 2,51 | – |
| 1.3 | Су агызуга | 2024 | 652,55 | - | - | - | - |
| | | 2025 | - | 1 | - | - | - |
| | | 2026 | - | 1 | - | - | - |
| | | 2027 | - | 1 | - | - | - |
| | | 2028 | - | 1 | - | - | - |

* Озак сроклы җайга салуның икенче һәм аннан соңгы елларына операция чыгымнарының база дәрәҗәсе Россия ФТХ 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 45 пунктында каралган формула буенча исәпләнә.
** «ТГК-16» АҖ өчен норматив табыш дәрәҗәсе билгеләнми.
*** Су агызуга тариф өчен «су югалту дәрәҗәсе» энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткече билгеләнми.
**** «ТГК-16» АҖ өчен «электр энергиясенең чагыштырма сарыфы» энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткече билгеләнми.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге